**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 декабрендәге 4619 номерлы карары**

## 2025 елда гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне һәм аларны әзерләүче педагогларны бүләкләү турында

«2022-2026 елларга Казан шәһәрендә мәгарифне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында, интеллектуаль яктан сәләтле һәм талантлы мәктәп укучыларын ачыклау һәм аларга булышлык итү, аларның иҗади сәләтләрен үстерү мөмкинлеген тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. 2025 елда гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә – Россия Федерациясе исеменнән чыгыш ясаган җыелма командалар әгъзаларына (алга таба – халыкара олимпиадаларда җиңүчеләр) Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләргә.

2. 2025 елда халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премиясен билгеләргә.

3. Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

4.1. халыкара олимпиадаларда җиңүчеләр һәм аларны әзерләгән педагоглар турында мәгълүматларны гомумиләштерүне тәэмин итәргә;

4.2. халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне һәм аларны әзерләгән педагогларны бүләкләүне тәэмин итәргә;

4.3. халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне һәм аларны әзерләгән педагогларны акчалата бүләкләү чыгымнарын 2025 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет язмасында каралган ассигнованиеләр чикләрендә «Мәгарифне үстерүгә юнәлдерелгән чаралар,

гомумшәһәр чаралары» 02 6 0243600 максатчан статьясы, 0709 бүлеге буенча 500 000,0 сум күләмендә гамәлгә ашырырга.

5. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 2 декабрендәге 4958 номерлы «2024 елда гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне һәм аларны әзерләгән педагогларны бүләкләү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 22 декабрендәге
4619 номерлы карарына
кушымта

**Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибе**

1. Казан шәһәре Мэры премияләре (алга таба − премияләр) интеллектуаль яктан сәләтле балаларга булышлык итү һәм аларны бүләкләү, укучыларның сәләтләрен тормышка ашыру мөмкинлекләрен киңәйтү максатыннан булдырыла.

2. Премияләр гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә – составы Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары укучылары арасыннан Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыклары белән расланган һәм Россия Федерациясе исеменнән чыгыш ясаган җыелма командалар әгъзаларына (алга таба – халыкара олимпиадаларда җиңүчеләр) һәм Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына бирелә.

3. Халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләүче педагогларга премияләр 2025 ел өчен бирелә.

4. Халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә премияләр күләме әлеге карар белән билгеләнә һәм укучыларның иң югары нәтиҗәләре буенча түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

- алтын медаль ияләренә – 300 000 сум күләмендә (тотып калынган салымны да кертеп);
- көмеш медаль ияләренә – 250 000 сум күләмендә (тотып калынган салымны да кертеп);
- бронза медаль ияләренә – 200 000 сум күләмендә (тотып калынган салымны да кертеп);

Премия бер призлы урын өчен түләнә һәм призлы урыннар санына бәйле түгел.

5. Педагогларның премия күләме әлеге карар белән билгеләнә һәм укучының иң югары нәтиҗәсенә карап түбәндәгечә билгеләнә:

- алтын медаль ияләрен әзерләгән өчен – 300 000 сум күләмендә (тотып калынган салымны да кертеп);

- көмеш медаль ияләрен әзерләгән өчен – 250 000 сум күләмендә (тотып калынган салымны да кертеп);

- бронза медаль ияләрен әзерләгән өчен – 200 000 сум күләмендә (тотып калынган салымны да кертеп);

Премия халыкара олимпиадада җиңүчене әзерләүче бер педагогка төп эш урыны буенча түләнә.

6. Кирәкле документлар исемлеге турында мәгълүмат Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең (алга таба – Идарә) рәсми порталында (https://obrazovanie.kzn.ru/) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 1 эш көне эчендә урнаштырыла.

Идарәнең рәсми порталында мәгълүмат басылып чыккан көннән алып 3 эш көне эчендә олимпиада уздыру чорында премия алуга дәгъва кылучылар укыган яки эшләгән белем бирү учреждениеләре түбәндәге документларны җыялар һәм Идарәгә кулдан-кулга тапшыралар:

- әлеге тәртипкә 1 номерлы (педагоглар өчен) яисә 2 номерлы (укучылар өчен) кушымтада билгеләнгән форма буенча гариза;

- яшәү урыны буенча теркәлү турындагы тамга белән паспорт күчермәсе;

- физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН);

- мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС) мәгълүматлары;

- Россия кредит оешмасында ачылган, түләү башкарылачак счетның реквизитлары;

- әлеге тәртипкә 3 номерлы кушымта яисә 4 номерлы кушымта белән билгеләнгән форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Башка документлар тапшыру таләп ителми.

7. Идарә 2025 елның 28 декабренә кадәр әлеге тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны аларның комплектлылыгына, аларда булган мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслегенә карап тикшерә, шулай ук Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрнең – Россия Федерациясе җыелма командалары әгъзаларының исемлеген раслау турындагы боеру документлары нигезендә белем алучыларның казанышларының дөреслеген тикшерә һәм премия алучыларның исемлекләрен раслый.

Премияне алучылар исемлекләренә әлеге тәртипнең 6 пункты белән билгеләнгән документларны тапшырган һәм аларны әзерләүче Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының халыкара олимпиадаларында җиңүчеләре яисә аларны әзерләгән педагоглары булган затлар кертелә.

Документлар билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, документларны тапшырган затларга премия алучылар исемлегенә кертелмәүләре турында гаризада күрсәтелгән электрон адреска электрон хат белән хәбәр ителә.

8. 2025 елның 29 декабренә кадәр Идарә, премия алучыларның исемлекләрен раслап, әмер чыгара. Әмер премия бирү өчен нигез булып тора.

9. Премия  Идарә тарафыннан гариза бирүчеләр тапшырган исәп-хисап счетларына әмер чыгарылган көннән алып 5 эш көне эчендә акча күчерү юлы белән түләнә.

Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибенә 1 номерлы кушымта (Форма)

Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы И.А.Ризвановка

____________________________________
(педагогның фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча))

____________________________________
(эш урыны, вазифасы)

__________________________________
(электрон почтасы)

**Халыкара олимпиадада җиңүчене – Россия Федерациясе Җыелма командасы әгъзасын әзерләүче педагогның Казан шәһәре Мэры премиясен түләү турында гаризасы**

Мин,

____________________________________________________________________,
(педагогның фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча))

гомуми белем бирү фәннәре буенча 2025 елда халыкара олимпиадада җиңүчене – Россия Федерациясе Җыелма командасы әгъзасын максатчан әзерләүче педагог булып торам

____________________________________________________________________,
(гомуми белем бирү фәнен күрсәтергә)

Казан шәһәренең гомуми белем бирү оешмасында төп эш урыны буенча:

____________________________________________________________________.
(белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың тулы исеме)

2025 елгы халыкара олимпиадада җиңү яулаган түбәндәге укучыларны әзерләүдә катнаштым:

1. ____________________________________________________________
(халыкара олимпиадада җиңүчеләрнең фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча))

Казан шәһәре Башкарма комитетының _______ елның ____________________ __________ номерлы «2025 елда гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне һәм аларны әзерләгән педагогларны бүләкләү турында»гы карары нигезендә миңа Казан шәһәре Мэры премиясен түләвегезне сорыйм.

Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибе белән танышуымны раслыйм.

Гаризага теркәп бирәм:

1. Шәхесне раслаучы документның күчермәсен.
2. Физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН);
3. Мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС);
4. Россия Федерациясе территориясендә урнашкан кредит оешмасында ачылган шәхси счетымның реквизитлары.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ______________ / | ____________________ |
| (имзалау датасы) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |

Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибенә
2 номерлы кушымта
(Форма)

Казан шәһәре Башкарма комитетының
Мәгариф идарәсе башлыгы
И.А.Ризвановка

______________________________________
(фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча))

______________________________________
(олимпиадада катнашу вакытына уку урыны)

______________________________________
(электрон почтасы)

**Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадада җиңүче – Россия Федерациясе Җыелма командасы әгъзасының Казан шәһәре Мэры премиясен түләү турында гаризасы**

Мин,

________________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча))

________________________________________________________________________
(гомуми белем бирү фәнен күрсәтергә)

гомуми белем бирү фәне буенча 2025 елгы халыкара олимпиадада җиңүче булып торам.

Казан шәһәре Башкарма комитетының _______ елның ___________________ __________ номерлы «2025 елда гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләрне һәм аларны әзерләгән педагогларны бүләкләү турында»гы карары нигезендә миңа Казан шәһәре Мэры премиясен түләвегезне сорыйм.

Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибе белән танышуымны раслыйм.

Гаризага теркәп бирәм:

1. Шәхесне раслаучы документның күчермәсен.
2. Физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН);
3. Мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС);
4. Россия Федерациясе территориясендә урнашкан кредит оешмасында ачылган шәхси счетымның реквизитлары.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ________________ / | ____________________ |
| (имзалау датасы) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |

Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибенә 3 номерлы кушымта (Форма)

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, ______________________________________________________________________,
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))
түбәндәге адрес буенча теркәлгән: ____________________________________________,
паспорт сериясе _______ номеры _____________ ________ елның «___» _______________ бирелгән
(бирелү вакыты)
_____________________________________________________________________________,
(документ биргән орган исеме, бүлекчә коды)

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9, 10 статьялары нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премиясен билгеләү һәм түләү максатыннан операторга – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (420111, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Большая Красная урамы, 1 йорт) автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), чыгару, куллану, шәхси үзенчәлекләрен бетерү, вакытлыча тыю, бетерү, юкка чыгаруны кертеп, минем шәхси мәгълүматларымны, аерым алганда:

1) фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта), туу датасы һәм урыны, адрес, эш вазифасы һәм урыны (булган очракта), уку урыны (булган очракта), паспорт мәгълүматлары;

2) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН);

3) мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС) мәгълүматлары;

4) Россия кредит оешмасында ачылган, түләү башкарылачак счетның реквизитлары;

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кайтарып алырга хокуклы булуым турында миңа аңлатылды.

Килешү аны имзалаган көннән гамәлгә керә һәм аны язма рәвештә кайтарып алганчы билгесез вакыт эчендә гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматлар минем тарафтан аңлы һәм ирекле рәвештә бирелде, алар чынбарлыкка туры килә һәм дөрес.

______________________________ ________________ / ______________________________
(имзалау датасы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премияләрен билгеләү һәм түләү тәртибенә 4 номерлы кушымта
(Форма)

**Балигъ булмаган баланың законлы вәкиленнән шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин,
________________________________________________________________,
(халыкара олимпиадада җиңүченең – Казан шәһәре Мэры премиясен алуга дәгъва итүченең законлы вәкиле (әтисе яки әнисе) фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча))

паспорт сериясе _______ номеры _____________ ____________________________________
(документны биргән орган)

_________________________________ бирелгән, бүлекчә коды: ____________________________
(бирелү көне)

даими теркәлү адресы: ________________________________________________________,

______________________________________________________________________
(балигъ булмаган затның фамилиясе, исеме, атасы исеме (тулысынча))

халыкара олимпиадада җиңүченең – Россия Федерациясе исеменнән чыгыш ясаучы составы Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы боерыгы белән расланган җыелма команда әгъзасының законлы вәкиле (әтисе, әнисе) буларак,

Россия Федерациясенең Гражданлык кодексының 26 статьясының 1 пункты, 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9, 10 статьялары нигезендә үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә гомуми белем бирү фәннәре буенча халыкара олимпиадаларда җиңүчеләргә һәм аларны әзерләгән Казан шәһәре гомуми белем бирү оешмалары педагогларына Казан шәһәре Мэры премиясен билгеләү һәм түләү максатыннан операторга – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (420111, Россия, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Большая Красная урамы, 1 йорт) автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча, шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), чыгару, куллану, шәхси үзенчәлекләрен бетерү, вакытлыча тыю, бетерү, юкка чыгаруны кертеп, әлеге ризалыкта күрсәтелгән минем шәхси мәгълүматларымны һәм күрсәтелгән балигъ булмаган балага карата шәхси мәгълүматларны, аерым алганда:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туу датасы һәм урыны, адресы, эш вазифасы һәм урыны (булган очракта), уку урыны (булган очракта), паспорт мәгълүматлары;

2) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН);

3) мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС) мәгълүматлары;

4) Россия кредит оешмасында ачылган, түләү башкарылачак счетның реквизитлары;

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү белән бәйле хокукларым һәм бурычларым, шул исәптән, шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта операторга хәбәр итәргә тиешлегем; операторга тиешле язмача гариза юллап, үз ризалыгымны теләсә кайсы вакытта кайтарып алырга хокуклы булуым турында миңа аңлатылды.

Килешү аны имзалаган көннән гамәлгә керә һәм аны язма рәвештә кайтарып алганчы билгесез вакыт эчендә гамәлдә була.

Шәхси мәгълүматлар минем тараftан аңлы һәм ирекле рәвештә бирелде, алар чынбарлыкка туры килә һәм дөрес.

| ______________________________ | ________________ / | ______________________________ |
|---|---|---|
| (имзалау датасы) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |